Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 3 (16)

9 февраль 2012 ел

## • Ике авыз сүз

3 февраль көнне Казан Мэры Ильсур Метшин КФУның юридик факультетында комиссия составында студентлардан дәүләт имтиханы алды. Килешү буенча укучы 8711 төркем студентлары дәүләт һәм хокук теориясе буенча белемнәрен сынады. 1991 елда әлеге факультетны «Хокук белеменә кереш» белгечлеге буенча тәмамлаган Ильсур Метшин 1999 елда аспирантураны бетерә һәм Мәскәүдә «Россия Федерациясе составында республикада хокук системасы» (Татарстан Республикасы мисалында) дигән темага диссертация яклый. 2010 елның декабреннән юридик факультетның Кайгыртучанлык советына рәис итеп сайлана. Дәүләт имтиханнары факультетта 8 февраль көнне төгәлләнде.

• • • •

6 февраль көнне КФУда Бөтенроссия «Мәгълүмати-коммуникатив технологияләр: теория һәм практика» фәнни-гамәли конференциясе үтте. Оештыру өчен журналистика һәм социология факультетының гамәли политология кафедрасы җаваплы иде. Конференцияне фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев ачып җибәрде. Пленар утырышта ТРның Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы Римма Ратникова, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Илшат Әминов, ТР Президентының мәгълүмати-аналитик идарәсе җитәкчесе Александр Юртаев чыгыш ясады. Шулай ук әлеге өлкәдә эшләүче күп кенә галимнәр, белгечләр хәзерге заманда мәгълүмати технологияләр, алардан дөрес файдалану, электрон хөкүмәт кебек проблемаларны күтәрде. Конференция кысаларында кафедра галимнәре тарафыннан эшләнгән «Гамәли политологиядә категорияләр һәм методлар» монографиясен тәкъдим итү һәм секция утырышлары узды.

• • • •

«ТРның 50 иң яхшы инновацион идеясе» конкурсы җиңүчеләре КФУның биохимия кафедрасы доценты Тимур Абдуллин инфаркттан коткару һәм даруларның тәэсир итү көчен арттыру проблемасын яктыртучы проектын, шул ук кафедра аспиранты Алсу Сәгыйтова дәвалау препаратларының кеше организмындагы авыруга тиз арада барып җитү проекты тормышка ашыра. Беренче проект җитәкчеләре кан һәм тукыма төкеректәге биомолекулаларны ачыклау өчен, төрле биохимик сенсорлар уйлап тапкан. Шундый ферментлар ярдәмендә миакард инфарктын табып булачак. Бу авырудан Россиядә елына 65 меңнән артык кеше үлә, 10 меңләбе инвалид кала. Сенсор кулланып тикшерелә торган анализның бер төре 10 сум тирәсенә чыга. Диагностиканы клиникадан тыш урыннарда да уздырып була. Икенче проект исә үзенең югары эффектлы булуы белән кадерле.

• • • •

12 февраль көнне УНИКСта Балалар университетының чираттагы лекцияләре уза. Алар «Компьютер уеннары ничек ясала?» һәм «Әкият ничек барлыкка килгән?» кебек кызыклы темаларга багышлана. Нәниләр үзләрен кызыксындырган сорауларга җавапны иртәнге унда биреге килеп таба ала.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Александр Бунтуков фотосы

# Фәннең дә үз көне бар

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Кичә Татарстан Фәннәр академиясендә ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов катнашында Бөтенроссия фән көненә багышланган тантаналы чара узды.

8 февраль Фән көне буларак РФ Президенты указы белән 1999 елдан уздырыла башлый. Бәйрәм унаеннан уку йортыбызга бик күп котлаулар килде. Фәннәр академиясендә узган тантаналы чарада академиянең президиум әгъзалары, фәнни хезмәткәрләр, ректорлар да катнашты.

ТР Премьер-министрының беренче урынбасары, икътисад фәннәре докторы Равил Моратов үз чыгышында фәннең бүгенге торышына басым ясады: «Бүген безгә фән буенча зур унышка ирешкән илләрдән үрнәк алырга, алар белән көндәш була алырлык дәрәҗәгә җитәргә кирәк. Россиядә фундаменталь тикшеренүләр өчен аз акча бүлеп бирелә. Җитәкчелекне аңларга да мөмкин, чөнки без ул акчалардан дөрес файдалана белмибез», – диде. Аның фикеренчә, гуманитар өлкәдә ирешелгән уңышларыбыз мактанырлык, аеруча тарихка зур игътибар бирелү сөенедерә. «Без нәрсә телибез һәм нәрсә эшли алабыз дигән аңлатмаларга бик якын торабыз», – дип өстәде.

Россия һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Е.К.Завойский исемендәге Физик-техник институт директоры Кев Салихов «Фән һәм җәмгыять» дигән лекция тәкъдим итте. Ул фәннең халыклар белән бәйләнеше, табигый һәм интеллектуаль ресурслар арасындагы көндәшлек кебек проблемаларны күтәрде. «Фән җәмгыять алдында зур җаваплылыкка ия. Ләкин җәмгыять тә фән алдында булган бурычын аңларга тиеш. Әлеге өлкә үссен өчен, тиешле шартлар булдырылу мөһим. Галимнәр дөресен генә сөйләсеннәр иде, ялган ачышлар, ялган фактлар белән алга китеп булмый. Безнең тагын төп бурыч – өйрәнелгән әйберне киләчәк буынга тапшыру, алар вакытларын әрәм итеп, без тикшергән әйберләрне өйрәнеп утырырлык булмасын», – диде галим.

Фән көне ул ниндидер котлауларга, яңа ачыш белән мактануга гына кайтып калырга тиеш түгел, тарихка исемнәре алтын хәрефләр белән язып куелган шәхесләребезне зурларга, искә алырга, рәхмәт сүзләре җиткерергә тиеш. Яңа ачышлар, галимнәрне санап бетерү мөмкин түгел, ә менә бөтен гомерен фәнгә багышлаган, үз мөмкинлекләрен буыннан-буынга тапшырып, зур династияләр булдырган галимнәр алай ук күп түгел.

*Рәсемдә: Хәбибуллин - Габдреевлар династиясе*

Ахыры 2нче биттә.

## • Ректорат яңалыклары

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

8 Февраль көнне ректоратның чираттагы утырышы узды. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин Үсеш программасының барышы турында сөйләде.



Эмир Фазлыйәхмәтов фотосы

Журналистика һәм социология факультетының Үсеш программасы буенча декан Васил Гарифуллин чыгыш ясады. Киләчәктә яңа юнәлешләр ачарга һәм факультетны институт дәрәҗәсенә җиткерергә дигән планнар бар.

Ләкин проблемалар да юк түгел. Рус әдәбиятыннан бердәм дәүләт имтиханын кертү татар бүлегенә студентлар туплауны катлауландыра. Бюджет урыннары да аз, контракт буенча укучылар бер елга 62 мең түли. Декан фикеренчә, авылдан килеп укучы студентлар өчен бу сумма артык зур. Шулай ук хезмәт хакының түбән булуы, татар журналистикасы тарихы һәм Фәннәр академиясендә әлеге өлкә буенча аерым институт булмау да проблема буларак карала.

Шунсы сөенечле: студентларга университет телевидениесе зур юллар ача. «UNIVER» телекомпаниясе эшчәнлеге белән Медиа-үзәк җитәкчесе Илдар Кәримов таныштырды. Бирелдә теорияне гамәлдә ныгытып булачак. Хәбәрчеләр хәтта материалны үзләре үк монтажлый алачак, чөнки заман журналисты бар өлкәне дә яхшы белергә тиеш. Иң соңгы технологияләр ярдәмендә ачылачак яңа лабораторияләр тәүлек дәвамында эшләргә мөмкинлек бирәчәк.

Ахыры 2нче биттә.

# Фәннең дә үз көне бар

**Башы 1нче биттә.**

Татарстанның мондый гаиләләрен зурлау күркәм традициягә әверелде. Быел шундый өч династияне зурладылар. Шаһидуллиннар гаиләсе башлыгы Роальд әфәнде – ил күләменә органик кушылмаларның спектроскопия өлкәсендә ясаган уңышлары белән танылган кеше. Вәлиев-Сөләймановлар династиясе гуманитар фәннәр өлкәсендә ясаган уңышлары белән игътибарга лаек. Хәбибуллин-Габдреевлар нәселенең башында торган галим Шәүкәт Хәбибуллин Казан дәүләт университетын тәмамлаучыларга яхшы таныш. Ул күп еллар дәвамында астрономия кафедрасы җитәкчесе, физика факультеты деканы һәм фәнни эшләр буенча проректор буларак билгеле. Әлеге династияләр турында тулырак без алдагы саннарда язачакбыз.

Бәйрәм, гадәттә, мактау сүзләреннән, бүләкләрдән тыш узмый. Ел дәвамында фән өлкәсендә зур уңышларга ирешкән галимнәрне ТР Президентының рәхмәт хаты, ТР Фәннәр академиясенең махсус премияләре белән бүләкләделәр. Академиягә әгъза итеп сайланган галимнәргә дипломнар тапшырылды. Шулай ук «2011 елның иң яхшы галиме» номинациясе җиңүчеләре дә билгеле булды, беренче мәртәбә «Ел эксперты» номинациясенә нигез салынды.

Бу чара тагын бер кат Татарстан Республикасы башкаласы үзенең фәнни кадрлары белән дан тотуын раслады. Казан федераль университетында яшь галимнәр әзерләү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Ректор Илшат Гафуров: «Без яңа үсеш юнәлешләре булдырдык. Геология, кара алтын һәм газ, фундаменталь медицина, биоинформатика өлкәсенә зур игътибар бирәбез. Яңа лабораторияләр, уку үзәкләре ачабыз. Өстенлекле фәннәр белән шөгыльләнүче яшь галимнәргә ай саен махсус премияләр биреп барабыз», – диде һәм барлык фән кешеләрен бәйрәм белән котлады. Ил күләмендә зур адымнар белән алга барган фән өлкәләрендә дә безнең галимнәребез сынатмас дип уйлыйбыз. Яңа ачышлар, яңа идеяләр безгә тагын бер баскыч югары күтәрелергә ярдәм итәр.

## • Ректорат яңалыклары

**Башы 1нче биттә.**

Заманчалаштырылган студиядә яздырылган тапшыруларны Интернет челтәре аша һәркем карый алачак. Телевидение хезмәткәрләре БДИга әзерләнү өчен видеодәресләр дә әзерли.

Бу уңайдан ректор Илшат Гафуров: «Журналист – иң куркыныч корал. Аларны тәрбияле итәргә кирәк. Кайчакта уйлаган фикерне әйтми калырга өйрәнәсе бар. Алар кайвакыт сорау да бирә белми. III курста рус теле, тарих, юриспруденция буенча белемнәрен барлау мөһим», – диде. Универсиада башкаласында спорт журналистикасы бүгенге көндә шулай ук иң зур проблемаларның берсе. «Бу өлкә буенча белгечләр кирәк. Я аерым юнәлеш, я махсус курслар булдыру шарт. Спорт буенча берни белмәгән кеше ничек итеп ул турыда сөйли алсын?» – диде Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты директоры Искәндәр Галиев.

КФУның Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү һәм яңадан әзерләү үзәгенең эшчәнлеге белән Педагогика һәм психология институты директоры Айдар Кәлимуллин таныштырды. Төрлеләр бүлегендә гражданнар оборонасы, КФУда гадәттән тыш хәлләрне булдырмау турында административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр штабы җитәкчесе Равил Вәлиуллин чыгыш ясады. Безнең университетта куркынычсызлык буенча бөтен шартлар да тудырылган.

Йомгаклап, ректор барлык хезмәткәрләрне Фән көне белән котлап, уңышлар теләде.

## • Мәсьәләгә бер караш

# «Күпләр Татарстанга кызыга»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

4 МАРТТА УЗАЧАК САЙЛАУЛАРДА ПРЕЗИДЕНТЛЫККА ДӘГЪВА КЫЛУЧЫ РОССИЯНЕҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ ВЛАДИМИР ПУТИН ТӘКЪДИМ ИТКӘН ЯЗМАЛАР ХАЛЫК АРАСЫНДА ЗУР КЫЗЫКСЫНУ УЯТТЫ. КЕМДЕР АНЫҢ ФИКЕРЛӘРЕ БЕЛӘН КИЛЕШӘ, КЕМДЕР БАШКА ПОЗИЦИЯДӘ ТОРА. БУ УҢАЙДАН БЕЗ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ СТРАТЕГИК ҮСЕШ БУЕНЧА ПРОРЕКТОР МАРАТ РӘШИТ УЛЫ САФИУЛЛИН БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.



***– Россия Федерациясе Премьер-министры Владимир Путин тәкъдим иткән язмада 2022 елга ил күләмендә берничә югары уку йорты булдыру турында фикерләр бар. Сезнеңчә, Казан федераль университеты алар исемлегенә керә алыр идеме?***

– Дөрестән дә, югары белем алу, уку йортына бәйле планнар бар. Россиянең инновацион үсешенә, көндәшлеккә сәләтлелеккә, креатив фикер йөртүгә зур игътибар биреләчәк, яңа проектларны тормышка ашыру буенча да идеяләр уңышлы. Белем бирүгә бәйле яңа җиһазларга, технологияләргә 25 млрд сум күләмендә акча бирелә. Минемчә, бу безгә мәгариф өлкәсендә яңа биеклеккә күтәрелергә, чит ил университетлары белән хезмәттәшлек итәргә ярдәм итәр.

***– Марат Рәшитович, КФУда нинди фәнни юнәлешләр буенча эш алып барыла?***

– 2010 елның сентябрендә Владимир Путин университетның Үсеш программасына кул куйды. Бу ике елда безгә 2 млрд акча бирелде. Без 5 зур юнәлешне тормышка ашыру өстендә эшлибез. Беренчедән, уку-укыту процессы. Яңа стандартларга – бакалавриат, магистратурага зур игътибар бирелә. Яңа лабораторияләр булдырылды, җиһазлар алдык. Икенчедән, фән үсеше. Шулай ук яңа технологияләр, инновация, лицензияләр булдырдык. Өченче юнәлеш квалификацияне арттыру, абитуриентлар белән эшләүне, укыту процессында Интернет-технологияләр куллануны күздә тота. Дүртенчедән, инфраструктураны киңәйтү юнәлеше буенча эшлибез. Монда IT системалар, төзекләндерү белән бәйле эшләр башкарыла. Һәм соңгысы: без идарә итү аппаратына зур игътибар бирәбез.

***– Бу юнәлешләрне тормышка ашыру өчен, нинди бурычлар куясыз?***

– Аеруча 4 өлкәгә өстенлек зур: физика, химия, биотехнологияләр, геология һәм кара алтын-газ технологияләре. Безнең республика бу өлкәләр буенча үсеш юлында. Галимнәребез төрле оешмалар белән хезмәттәшлек итә. Яңа дарулар җитештерү буенча эш башларга җыенабыз.

***– Бераз сәясәткә керсәк, Россиянең икътисади хәлен ничек бәялисез?***

– Россиянең матди күрсәткечләре яхшы. Хәзерге көндә иң зур проблема – булган акчаны дөрес файдаланмау. Без аларны модернизациягә җибәрергә, яшәү шартларын яхшыртырга тырышабыз. Коррупция, дәүләт идарәләре белән бәйле проблемаларны хәл итми торып, уңышка ирешә алмаячакбыз. Бигрәк тә мәгариф өлкәсендә. Акчаны күбрәк иң мөһим төбәкләрне үстерүгә юнәлтергә кирәк. Аннан соң без җирдә булган байлыкны сакларга өйрәнергә тиеш.

***– Сезнеңчә, Россия алдынгы илләрне куып җитә алачакмы?***

– Төп бурыч кемне дә булса куып җитү яисә узып китү түгел бит. Без чит ил базарында үз урыныбызны булдыру максатын куярга тиеш. Кемнән дә булса күчереп алып эшләргә түгел, ә үзебезгә яңа технологияләр уйларга кирәк. Менә Сингапур ничек үсә? Аларның табигый байлыклары да юк бит. Яңа идеяләр аркасында алга чыгалар. Безгә дә шулай итәргә кирәк, ә сату күп булган өлкәгә кысылырга түгел.

***– Марат Рәшитович, ничек уйлыйсыз: Владимир Владимирович Путин язмасында җитешсез яклар бармы?***

– Кеше, социаль фактор, базар икътисады, татар моделе турында фикерләр җитеп бетми, миңа калса. Артык зур проблемалар күтәрелә. Ә кешене нәрсә борчый? Яшәү-торак шартлары, хезмәт хакы, яшәү стандартлары, сәламәтлек, куркынычсызлык кебек сораулар кызыксындыра. Беренче урында кеше тора. Аннан соң гына капитал килә. Республикабызның инфраструктурасы яхшы. Идел буендагы күп кенә төбәкләрдә, субъектларда еш булырга туры килә. Андагы халык Татарстан халкы кебек яшәргә хыяллана. Димәк, күп төбәкләр арасында безнең республикабызның абруе зур. Шул исәптән, университетыбызныкы да.

***– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Марат әфәнде.***

*Матбугат үзәге ярдәме белән әзерләнде*

## • Туган тел сагында

# Татарлыгың ничә процент?

**Рамил ХАННАНОВ**

2 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТҮЛӘҮСЕЗ ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ АЧЫЛДЫ. ИКЕНЧЕ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕН ӨЙРӘНЕРГӘ 850 ЛӘП КЕШЕ ТЕЛӘК БЕЛДЕРГӘН.



Курсларның оештыру җыелышында халык, Актлар залына гына сыймыйча, тагын 3-4 лекция залын тутырган иде. Алар арасында дәүләт хезмәткәрләре, социаль яклау, пенсия фонды, бизнес-структура вәкилләре, табиблар, журналистлар, мәктәп укучылары һәм лаеклы ялда булган шактый гына өлкән яшьтәгеләр бар иде. Оештыручылар әйтүенчә, кимендә 60 төркемгә бүленеп, тел өйрәнүчеләр атнага 2 тапкыр 3 ай дәвамында белем эстиячәк.

Татар теленә ихтыяҗның артуымы бу? Әллә бушка булгач, ябырылып калыйк диюләреме? Сәясәтне аңлап бетерүе минем өчен авыр булды. Кырмыскалар төсле тезелешеп, Актлар залына агылган халык массасыннан кемнедер аерып алып, фикерләрен белү мөмкин түгел иде. Моның каравы, Интернетның төрле сайтларында, социаль челтәрләрендә курсларга кадәр дә, аннан соң да көчле фикер алышулар, бәхәсләр тынмый. Шулар арасында иң әһәмиятлесе – оештыручылар да, вакытлы матбугат чаралары да үзләренә терәк итеп алган журналист Игорь Севрюгин язмасыдыр. Канында 25% татарлык булган егет: «Татарлык минем йөз чалымнарымда гына сакланган», – ди һәм үзенең туган теле рус теле булуын әйтә. Шул ук вакытта татар телен өйрәнүнең әһәмиятлелеген 5 дәлил белән беркетә:

1. Мин 20 ел янәшә яшәгән халыкның телен һәм мәдәниятен (ә тел – мәдәниятнең бер өлеше ул) хөрмәт итәм.
2. Кешеләрне аңларга телим!
3. Татар телен белеп, үземнең көндәшлеккә сәләтле булуымны аңлыйм.
4. Күбрәк тел белгән саен, шәхес буларак үсү мөмкинлегең дә зуррак.
5. «Телләрнең юкка чыгуы кызганыч» (тәрҗемәче, филолог Нина Аврора-Раабен сүзләре).

Күрәсең, «туган тел каннан дәшә» гыйбарәсе үз көчен төрле чорларда да сиздерә. Эх, кайбер җитәкчеләрнең дә канында 5-10% кына булса да татарлык акса!

ТР Дәүләт Советында узган матбугат конференциясендә РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов республикабызда телләрнең укытылу дәрәҗәсенә басым ясаган иде: «Кайсы телне күпме укытырга кирәк икәнлеген Федераль закон нигезендә һәр төбәк үзе билгели. Мин монда, сан турында сөйләшүләрне читкә куеп, сыйфат турында сөйләшергә чакырыр идем. Иң мөһиме: атнага ничә тапкыр рус яки татар теле дәресе укытылу түгел, ә аларның ничек итеп укытылуы. Рус балаларының – татар телен, татар балаларының рус телен үзләштерүе түбән дәрәҗәдә. Укытуның сыйфаты турында ныклап уйланырга кирәк».

Сүзләрдә хаклык бар гына түгел – күп! Әгәр дә ипилек-тозлыкны балалар бакчаларында, мәктәпләрдә үзләштергән булсалар, 2 февраль көнне татар телен башлап өйрәнергә йөгерүчеләр саны шул кадәр үк булыр иде мени?! Балалар чиста татар телендә тәрбияләнергә тиешле бакчаларда татарча белгән нәниләр саны төркемгә 2-3! Мәктәп-гимназияләр турында сүз дә куертасы килми.

Чиста рус милләтеннән булган бер дустым бар. Ул минем белән татар телендә аралашырга ярата. Каян беләсең син татарча, дигән соравыма ул серле генә елмая да җавапсыз кала. Берсендә моның өенә көтмәгәндәрәк барып кердем, фатиры беренче катта, җәйге челләдә тәрәзәсе киереп ачылган, ә аннан ишелеп татар җыры агыла. Менә хикмәт нидә икән! Ахырдан үзе дә әйтте: «Татар милләтенең бар үзенчәлеген, телен, җанын, рухын бары аның культурасы, җыры-моңы аша гына аңлап була». Тагын хаклык! Методик әсбаплар, укыту ярдәмлекләре, программа һәм дәреслекләр төзегәндә, бераз уйланырга урын бар.

Филология һәм сәнгать институтында башланып киткән татар телен өйрәнергә теләүчеләр арасындагы омтылыш-теләкләр, матур традициягә әйләнеп, сыйфат турында җитәкчеләрдә шик уятмас дип уйлыйм.

● Мәрхәмәтлелек



# Бер җылы сүз җитә

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Чаллы шәһәрендә балигъ булмаган балалар өчен «Асылташ» социаль-тернәкләндерү үзәге эшли башлаганга 10 ел тулды. КФУның Яр Чаллы филиалы әлеге үзәк белән 6 елдан артык хезмәттәшлек итә.

Филиалның журналистика һәм социология факультеты студентлары биредә беренче мәртәбә Яңа ел бәйрәме уздыра. Ә Беренче Президент Минтимер Шәймиев игълан иткән Хәйрия елы уку йорты белән үзәк арасындагы хезмәттәшлекне тагын да ныгыта.

Үзәктә тәрбияләнүчеләр өчен ел саен концерт-лекция залында Игорь Лерман җитәкчелегендәге «Провинция» камера оркестры концерт оештыра. Һәр Яңа елда студентлар әкияти тамаша әзерли. Кыш көне кар көрәргә булышалар, зур тау ясыйлар.

«Студент еллары – балаларга» акциясе кысаларында җыелган акчага акыл сәләтен үстерүгә ярдәм итә торган китаплар, төрле юнәлештәге энциклопедияләр алып бирәләр, шулай ук уку кирәк-яраклары, кием-салымнар бүләк итәләр.

Язгы кояш елмаеп карый башлагач, саф һавада төрле спорт ярышлары уздыралар. Балалар рәхәтләнеп ял итә, күңел ача. Ярышларда җиңүчеләргә дипломнар, ә барлык катнашучыларга истәлекле бүләкләр тапшыралар. Кечкенә тәрбияләнүчеләр дә мондый чаралардан читтә калмый. Аларга филиалның спорт залында Сәламәтлек көне уздырыла. Шулай ук «Асылташ» балалары «КФУның Яр Чаллы филиалы чибәре» конкурсының алыштыргысыз җанатарларына, даими тамашачысына әверелде.

Студентлар киләчәккә дә зур планнар белән яши. Өлкән сыйныф укучылары белән профориентацион әңгәмәләр, «түгәрәк өстәл»ләр, өмәләр, концерт-очрашулар уздырырга ниятлиләр.

Тырыш студентларның яхшы итеп укырга да, уку йорты эшчәнлегендә булышырга да, концерт-фестивальләрдә, фәнни конференцияләрдә катнашырга да вакыты җитә. Ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне дә игътибарсыз калдырмыйлар. Ә аларга күп кирәкми, бары тик бер җылы сүз җитә.

● Кечкенә галимнәр

# Көянтә

**Рифә РАХМАН**

**(Дәвамы. Башы 1-2 (14-15) саннарда)**

...Нәни көянтәгә асылган чиләкләрдә әле кайчан гына йөгерә-йөгерә бакчага су ташып йөргән иде ул. Ат суйганда, малчыларга мунчадан җылы су алып чыккан, инеш суыннан җыйган акшар ташларын күтәреп, шушы бакча сукмакларыннан күтәрелгән. Кемнәр иңнәрендә чайкалырсың син, көянтә? Кемнәргә минем сагышлы көннәрем хисләрен илтерсең дә, чиләкләренә тамып, суларын чайпалдырырсың?!

...Артбакча ягында Сусылуны болай да сагыш баса. Элегрәк еллар булса, шул тирәдә эшләп йөргән әтисе, инеш буеннан күтәрелгән кызының җилкәсеннән авыр чиләкләрне җиргә төшерергә булышыр иде. Ул юк. Көянтә юк. Яшьлек кире кайтмаслык еракта калган. Уңга караса – сирәк булса да, аның янына да төшкәләгән инеш коесының торнасы башларын кыегайткан, сулга караса – Ерак чишмә юлларын басып киткән чытырманлыклар өстендә ала каргалар көтүе бөтерелә. Көянтәсез калган көннәрне үк инеш буйлары чүп-чар оясына әверелә башлаган кебек иде инде. Киләчәктә кирәге булмас көянтәләрнең дә, су өйгә үк керер, дигәндер инде әнисе. Ә бит ялгышмаган. Акшарлары торбаларны буардай кое сулары чәйнекләргә өй эчендәге краннардан ага...

Каргалар бөтерелә дигәннән, ул чакта да баш очында өер-өер очкан иде алар.

– Кар, кар, кар, – дигән булалар. Йөрәк өсләреңә кар куеп тор диюләреме бу? Мал суйган көннәрдә кар өстендә яткан эчәгеләрне уйлап шаулашуларымы? Каргалар ымлыгыннан тоемланган сүздән дә тәненә суык йөгерә...

...Югалту сагышы бераз басылгач, Сусылу ишегалдына чыкты. Бераз торасы калган әле, торасы – тынычланасы... Чыкта һәм соңрак әнисе бүләк иткән, әле хәзер дә кыз җилкәсенә еш кунаклаган көянтәгә карап катты. Аны да югалтыр микән ул кайчан да булса мәңгегә?!

Озакламый кыз ерак бабаларына кунакка китеп барды. Өскекүлдә су ташырга биргән көянтә кечкенә инде, олыраклары көйсез, җилкәне кабарта, авырттыра. Югалту сагышы монда басылыр иде кебек, бары тик көчәйде генә. Җитмәсә, бергәләп авыр йөкләр тарткан, урман юлларын көненә кырыкмаса кырык ураган бабасы да картайган. Мәңге картаймый торган, бабасы йөрәгеннән Сусылуныкына күчеп утырган эшкә теләк кенә җаныннан китми йөдәтә. Өлкәннәр теләге кабул булса да булыр икән.

...Инде оҗмах түрләре язсын мәрхүмкәенә. Башкаларга бер эш тә калдырмый яшәгән кебек иде. Көрәкләре дә, балталары да һаман эштә... һаман абзар артына сөялгән, кадакларга эленгән, бүрәнә араларына кыстырылган килеш – барысы да үз урынында. Барысы да эш көтә. Сусылуны сагынган көянтәләр дә инде яңа йортның шул ук урындагы болдыр кадакларында...

Көянтә дигәннән, җанына кадерлеләрен югалта барса да, аларны яңалары оныттырмаса да, үз гомерендә Сусылу көянтәләрнең күп төрлесен күрде. Ире белән бергә чакта яшәгән Әмәт тавындагы йортларына балчык-таш, су ташыганда да аның җилкәсен җитәрлек ашады көянтә. Әйе-әйе, вакларыэреләре, зәңгәрләре-күкләре алмашына торса да, ни утка ягылган, ни кешегә сатылган дигәне онытылмады, гомер юлларында югалткан кешеләрен дә алмаштырырлыклары табылмады.

Бабасы белән әнисе алып биргән тәүге көянтәләр генә аның җилкәләрен авырттырмаслык җай, уңай уелган булган икән. Аларга тагылган чиләкләр дә артыгын авыр түгел иде әле, тар, юка җилкәләрендә тартып барган тормыш йөге дә яшь, тере гәүдәне сыгылдырмаслык...

**(Ахыры киләсе санда)**

● Әйе-юк

# Армиягә барабызмы?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Шушы арада Президентыбыз армия сафларына алынган егетләргә ай саен икешәр мең сум күләмендә акча күчереп бару турындагы указга кул куйды. Әле былтыр гына 400-500 сум алып торган солдатлар өчен, әлбәттә, шактый зур күтәрелеш. Әлегә бу тәҗрибәне 2012-2013 елларга гына керткәннәр. Кызык, нәтиҗәләре нинди булыр икән? Үземә генә фикер йөртү кыен булганга, төрле яшьтәге ир-егетләргә мөрәҗәгать иттем. Әлеге күңелле факт аларның хәрби хезмәткә бәйле карашларын кайсы якка үзгәртте икән?

## Әйе



***Илдар Якупов, 11 сыйныф укучысы:*** «Минем армиягә бару теләге алдан ук бар иде инде. Ә болай акча да өстәгәч, шәп бит бу! Начар җирләргә генә эләгергә язмасын. Гомумән, әгәр дә үзеңне күрсәтә белсәң, армияне куркыныч җирдер дип уйламыйм!»



***Рөстәм Нурмиев, Тарих институты, I курс:***

«Россия гражданины үзенең иле алдында булган бурычын намус белән үтәргә тиеш! Бу мәсьәләгә килгәндә: әгәр ул үз иленең патриоты түгел икән, дәүләт нинди генә шартлар тудырмасын, анда барыбер бармаячак! Үземнең армия сафларына бик тә барасым килә, чөнки физик яктан да һәм шулай ук мораль яктан да чыныгасың бит, җитмәсә, шундый законнар чыгып торганда! Патриот буларак, мин бик шат, димәк, хөкүмәтебез тик утырмый!»




***Айнур Кыямов, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты, IV курс:***

«Һәр егет армиядә булырга, ил каршында бурычын үтәп, хезмәт итеп кайтырга тиеш дип уйлыйм. Әлбәттә, мондый указдан соң армиягә үз теләкләре белән баручы егетләр саны да бермә-бер артыр. Шулай да, миңа калса, бу гына армия проблемасын тулысынча чишеп бетерә алмас. Минемчә, армияне килешү нигезенә корырга кирәк. Кайбер таләпләрне дә катгыйландырсалар, хәрби хезмәт итүнең сыйфаты да, куркынычсызлыгы да артыр иде!»



***Зиннур Хөсәинов, инглиз теле укытучысы, 30 яшь:***

«Миңа калса, бу армиядән качып йөрүче егетләрнең санын киметер. Алга таба бик яхшы стимул дип уйлыйм!»



***Рамил Йосыпов, 24 яшь, хәзерге вакытта хәрби хезмәттә:***

«Яхшы инде бу! Тамак туячак дигән сүз бит!!! Ләкин армиядәге тәртипләрне яхшырту өстендә эшләсәләр, күпкә уңышлырак булыр иде. Мәсәлән, армиядә яхшы хезмәт итүчеләргә ниндидер уңайлыклар өстәп, ә тәртип бозучыларга кырыс җәзалар булса, бәлки, азрак үзгәрешләр дә барлыкка килер иде! Ә хезмәт иткәндә, чын ир-ат буларак формалашасың, диюләре бик дөрес сүзләр!»



***Фирзәр Тимербаев, 20 яшь, хәрби хезмәттән күптән түгел кайткан:***

«Ай саен 2 мең кереп торса, ул бик әйбәт инде! Безгә 400 генә бирделәр, ул гап-гади кирәк-яракларга да җитми иде! Мондый указлар күптән кирәк булган ул!»



***Рамил Мифтахов, хәрби хезмәт итеп кайткан, 24 яшь:***


«Яхшы, әлбәттә! Чөнки без хезмәт иткәндә, бу сумманың чиреген генә ала идек!Яшереп тормыйм: 460 сум алдык бер айга! Менә шунда инде акчаның кадерен дә белә башлыйсың! Ә 2 мең – бу бик күп акча!»

## Юк



***Илназ Гайнетдинов, Икътисад һәм финанс институты, III курс:***

«Армия ул – тәртипсезлек, дедовщина! Әллә нинди законнар кертсәләр дә, армиягә бармас идем!»



***Фердинас Гарипов, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, III курс:***

«Бик яхшы указ. Ләкин бу күп акча түгел инде... Ул бит елга 24 мең сум була. Бер 120-240 меңнәр булса, уйларга мөмкин».



***Илнар Нотфуллин, Филология һәм сәнгать институты, IV курс:***

«Минем 1200 сум студент стипендиясенә өстәп, әти-әни ярдәм итсә дә, бер айга ул акча гына җитми... Ә армиядә? Анда җитә дип уйлыйсызмы? Әлбәттә, юк! Һәм, гомумән, хезмәт итәр өчен акча бирү – берни дә бирми. Хезмәт итәр өчен армиядә тәртип булырга тиеш. Шул очракта гына егетләр анда барачак...»



***Аяз Мусин, КДЭУ, энегетика факультеты, V курс:***

«Кызык инде безнең илдәге хәлләр... Әмма бу закон гына армиядәге тәртипне үзгәртмәячәк. Анда аена 2 мең акча алганчы, мин монда яхшы эшкә урнашам!»



***Айнур Халиев, Филология һәм сәнгать институты, III курс:***

«Мин, Аллага Шөкер, армия сафларында булмадым һәм моңа сөенәм дә... Кайберәүләр, бәлки, куркак дип гаепләр, тик хәзер анда баруның ниндидер файдасы бардыр дип уйламыйм. Беркөнне шулай Интернет челтәреннән армиядәге «бабайлык»ның видеоязмаларын карап утырдым, коточкыч анда... Акча арту белән генә тәртип үзгәрмәячәк! Иң беренче тәртип урнаштырсыннар, аннары хезмәт итү турында уйлап карармын...»



***Булат Зиатдинов, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, II курс:***

«Мин армиядә булмадым. Бу закон турында да беренче тапкыр ишетәм. Гомумән, барырга да җыенмыйм... Тәртипсезлек бит анда, нинди генә акча түләсәләр дә...»



***Радик Ситдиков, Казан дәүләт энергетика университеты, II курс:***

«Минемчә, армия сафларында бер ел буе хезмәт итү ул вакытны бушка әрәм итү генә. Ватан алдында үз бурычын үтәп кайткан дусларым да шулай ди. Андагы тәртипсезлекләр бер дә үзенә тартып тормый шул. Ләкин армиядә булмаган кешене яхшы эшкә алмыйлар, диләр...»

*Менә, дуслар, шундыйрак җаваплар. Дөрестән дә, шундый указлар чыгарып кына хәрби хезмәт итәргә ашкынып торучылар артса ярый. Егет кешенең канында андый теләк булмаса, акча белән генә алдап-йолдап булырмы икән?!*

• Халәт

# Яшьлек хатирәләре



**Мөнир НИГЪМӘТ,**
КФУның Алабуга филиалы доценты

Техник яктан югары сыйфатлы булып чыккан «DARELFӨNYN» газетасы белән танышкач, кәефем күтәрелеп китте һәм язарга булдым.

Моннан 35 ел элек В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнарына ия Казан дәүләт университетын тәмамлаган бер шәкерт мин. Үзем, университетның төп бинасында I катта буфет кырыенда гына урнашкан «Комитет комсомольской организации» бүлмәсенә кереп, комсомол билетын ташлап чыксам да, шуннан соң алмашка килгән буталчык, болганчык бер генә партия вәкиле булмасам да, «Ностальгия» каналын юкка гына карамыйм. Чөнки сагынам шул елларны, шул ук вакытта барыбер дә бүгенге позитив дип игълан ителгән үзгәрешләргә ышанып бетә алмыйм.

Мин укыган елларда (1972-1977) һәм аннан да алдарак татар теле һәм әдәбияты бүлеге дип тарихка кереп калган, атаклы химик Арбузовның химиклар бинасында татар милләтенең төп оеткысы булып күпереп чыккан югары сыйфатлы белем алуга ирешкән хәзерге татар зыялыларын саный башлыйкмы?! Кирәкмәстер, алар бик күп, чынлап та, лаеклылары да бар һәм...

Бу бүлек милләтне цементлаштыручы йодрык булып оешты, халкыбыз өчен бер үзәк, югары белем бирә торган тыйнак үзәк булып эшләп китте. 1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлеге башта кайда урнашкан булган, кайда үзенең эшчәнлеген башлавы хакында безгә хәбәр бирмәделәр, нишләптер.

Изге күңелле тел һәм әдәбият галимнәренең вафат булганнарына сират күпереннән кичәргә язсын, Аллаһы Тәгалә исәннәренә тазалык-саулык, түземлек бирсен. Нәкъ шушы бүлектә генә милләт мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә әзер дип табылган «штучный, качественный кадрлар»ны әзерлиләр иде. Гафу итегез, монысы ностальгия, бәлки аз гына мактанудыр да.

Безгә үзе бик тыйнак, ләкин белемле, беркайчан да хезмәттәшләренә, бигрәк тә студентларына караңгы чырай күрсәтми торган мөлаем тел галиме Сәгадәт абый Ибраһимов синтаксис курсын укытты, шулай ук семинар дәресләре дә алып барды. Нишләптер, бәлки яшьлек шуклыгым беләндер, прототип итеп аны алып, бер юмористик хикәя язып ташлаган идем. Шуны XXI гасыр студентларына юллыйм. Бу матур газетагызны кулга төшерү бәхетенә ирешсәләр, курсташларым да сөенер иде.

**Редакциядән.**

*Хөрмәтлеукучылар! Сез Мөнир әфәнденең мәкаләдә телгә алынган хикәясе белән алдагы саннарда таныша аласыз.*

• Тәнгә – мунча, җанга – юк

# Кызлар «теоремасы»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Беркөнне күптәнге танышым шалтырата. Гел күрешеп булмый, эш, шәхси проблемалар, ара ерак, дигән булабыз. Әле ярый шул телефон бар. Бөтен яңалыкларны ишетеп, белеп торырга. Иптәш кызым бер дусты сөйләгән хәл белән уртаклашты. Шул көннән бирле уйланып йөрим. Сезгә дә сөйлисем килә. Кем әйткәндәй: «Ниендәге ниеңне нитә күрмә ниенә, ниеңнең дә ние бардыр, ул да нитәр ниенә», – булды инде бу.

Яр Чаллы шәһәрендә бер төркем егетләр, кызларның чын йөзен ачарга теләп, кызыклы гына тикшеренү уздырырга уйлыйлар. Эксперимент үткәрү өчен, иске 412 модельле, кызгылт-сары төстәге «Москвич» алына. Тимер атның яше дә зур, тавышы да яхшы гына чыга, ләкин йөрерлек хәлдә. Шулай ук «БМВ530i» дигән машина сайлана. Егет кешегә, танымасыннар өчен, бейсболка, кара күзлек кидерелә.

Тикшеренү түбәндәгедән гыйбарәт: тротуар буйлап баручы чибәр кыз яки кызларны табарга кирәк, ансы мөһим түгел. Шуннан соң кыз белән әңгәмә корыла һәм «Москвич» белән кирәк урынга алып барып куярга тәкъдим ителә. Барлыгы 15 кызга шул тәкъдим белән мөрәҗәгать итәләр. 14 е «Москвич»та йөрүдән баш тарта, төрле котылу юллары уйлап таба. Кемдер дуслары белән очрашуга ашыга, кемнедер егете көтеп тора, берсе әнисе янына шифаханәгә йөгерә, икенчесе укуга соңга кала.

Егет кеше бер тимер аттан икенчесенә күчеп утыра, киемнәрен алыштыра. Шул ук әңгәмә һәм тәкъдим белән шул ук кызларга мөрәҗәгать итә. Егет инде хәзер «крутой мачо». 15 кызның бары тик берсе генә егетне таный, чөнки ул бейсболкасын салырга оныта. 14 кыз («Москвич»ка утырган туташ катнашмый) машинага утырырга ризалык бирә. Иномарка белән килеп туктагач, кызларны утырырга күндерү өчен иң күбе 80 секунд вакыт үтә. Аеруча әнисе янына шифаханәгә ашыгучы кыз бик тиз ризалаша.



Машинага утырган кызларның, дөресен белгәч, сөйкемле генә йөзләре нинди кыяфәткә килгәнен чамалыйсыздыр. Үзегезне шул урынга куеп карагыз әле...

Нәтиҗә ясап, шуны гына әйтергә мөмкин: кызлар өчен егет кешенең ни кигәне, нәрсә мыгырдаганы мөһим түгел, аларга (безгә дип әйтергә тел әйләнми) «принц»ның нинди «атта» йөрүе һәм кесә калынлыгы беренче урында тора. Мондый нәтиҗәләрдән соң, егетләр, кызлар белән бәйле, һаман төгәл җавабы булмаган теореманы тагын бер кат исбатлап, дөреслеккә бер адым ясый. Кызганыч, аларны аңларга була... Шунсы гына куанычлы: эксперимент «Москвич»ның дәрәҗәсен күтәрә, ул да машина бит.

Ә Совет машинасына утырырга ризалашкан кыз егетләрне таң калдыра. Алар бу машинага утырган һәр кыз өчен роза чәчәге әзерләп куйганнар. 15 не!!! Димәк, аларның өметләре зурдан булган. Ә бу купшы букет бары тик бер кызга гына эләгә. Машинага утырырга ризалашуын нәфис зат руль артындагы егетнең күңеленә хуш килүе белән аңлата. Ә машинаның, кесә калынлыгының нинди булуы аны борчымый.

Арабызда андыйлар барлыгы тынычландыра бераз. Соңгы елларда бигрәк нәфислегебезне, гүзәл сыйфатларны югалта башладык бит. Хәзер (әйтергә туры килә инде, шул заттан булгач) бөтенләй башка таләпләр, хыял-максатлар белән яшибез. Яхшы машинасы, шәһәр үзәгендә, ким дигәндә, 3 бүлмәле фатиры булган егетләр кирәк безгә. Купшы тун, алтын йөзек, кыйммәтле күлмәкләр алып бирергә, кафе-рестораннарга йөртерлек акчасы булырга тиеш сайлаган егетләребезнең. Ләкин беркем дә уйлап карамый: яңа гына уку йортын тәмамлаган, мескен студент елларыннан зур тормыш юлына аяк басып килүче «сөйгән» ярның андый акчасы каян булырга мөмкин икән?! Бай әтинең акчасын туздыручы егетнең киләчәге бар микән соң? Булган байлыкны акыл белән туздыра да белергә кирәк бит әле.

Кызларны да, егетләрне дә гаепләп, ниндидер яла ягу дөрес булмас иде. Бер начар кеше аркасында бөтенебез зыян күрергә мөмкин. Мондый экспериментларга барып җитәрлек булгач, егетләрнең үзәкләренә үткәнбез инде.

• Идел кинлекләре

# Уярня



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

*Уярня бәйрәме Шорыкйолдан (Яңа ел вакытларында уздырыла торган бәйрәм) соң 7 атна узгач, февраль ахыры — март башында, яңа ай туган вакытта бәйрәм ителә. Ул дүшәмбедән башланып, бер яки ике атна буена бара.*

*Уярня — мари халкының бик борынгыдан сакланып калган, кышны озатып, язны каршылауга багышланган бәйрәме. Русларның Май чабуына (Масленица) охшашрак. Бәйрәмнең үзенчәлекле ягы — кышкы һәм язгы йола элементларының бер-берсенә яраклашуында. Ә үткәрелә торган йолаларның нигезендә табигатьнең уяна башлавы, җирнең уңыш бирдерүче көчләренең яңадан туулары, гаиләләрнең киләчәк уңышларына хәзерлек һ.б. шундый аграр культ ята.*


*Бәйрәм, әйткәнебезчә, дүшәмбе көнне иртән Уярня курыктан (Масленица тавы) чана шуудан башлана. Элек заманнарда чана шууга бик зур әһәмият биргәннәр. Борынгылар чана шуу төрле чирләрдән котылырга ярдәм итә һәм көч өсти дип ышанганнар. Хатын-кызлар киләсе елда уңыш күп булсын дигән теләк белән, чана шуганда, карга бодай, арыш, киндер орлыклары сипкәннәр. Көнкүрештә кулланыла торган табак, тагаракларга, арыш көлтәләренә утырып шуганнар. Бигрәк тә, таудан парлашып, аякта басып төшү традицион булган. Авылны усал көчләрдән арындыру өчен, кыңгырау таккан атларга утырып йөргәннәр. Кызыклы уеннар уйнаганнар.*

*Ризык әзерләүгә дә зур игътибар биргәннәр. Коймаклар, солы камырыннан түгәрәк бавырсаклар (уяча) һ.б. мул итеп пешерелгән. Күп итеп сыра әзерләнгән. Бәйрәм табынында ризык бай булса, ел буе тук тормышта яшәрбез дип өметләнгәннәр. Бер-берсенә кунакка йөргәннәр.*

*Бәйрәмнең соңгы көнендә Уярня белән саубуллашу йоласы үткәрелгән. Бәйрәм вакытында җыелган барлык чүп-чарны җыйнап, уртага куелган салам көлтәсенә ут төртеп: «Уярня каен!» («Масленица китте!») - дип кычкырганнар. Ә инде ут сүрелә башлагач, егетләр һәм кызлар учак аша сикергәннәр. Көлне басуга сипкәннәр. Кайбер мари авылларында бу бәйрәмнең йолалары бүген дә сакланган әле.*

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

«DARELFӨNYN» газетасы редакциясе хәзер түбәндәге адрес буенча урнашкан: Профессор Нужин урамы, 1/37 йорт (керү – УНИКС спортблогына каршы якта), III кат, 318 кабинет.




DARELFӨNYN университет
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла